**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» марта 2020 с. Тюлячи № 147

2004-2005 елда туган яшүсмерләрне хәрби исәпкә куелганчыга кадәр медицина белән тәэмин итү турында

«Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы, Россия Федерациясе Саклану министрының һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә әзерләүне медицина ягыннан тәэмин итүне оештыру турында» 2001 елның 23 маендагы 240/168 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 2 мартындагы 456-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2004-2005 елда туган яшүсмерләрне хәрби хезмәткә әзерләү буенча дәвалау-савыктыру чаралары планын расларга.

2. «Теләче үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибына (Галиуллин И.И.) тәкъдим итәргә:

- 2020 елның 1 июненә кадәр яшүсмерләрне диспансерлаштырган өчен җаваплы зат билгеләргә;

- 2020 елның 1 июненә кадәр билгеләнгән документларны рәсмиләштереп, 2004-2005 елда туган яшүсмерләр арасында план буенча профилактик медицина тикшерүләрен, дәвалау-савыктыру чараларын үз вакытында, тулы һәм сыйфатлы үткәрүне тәэмин итү;

- 2020 елның 25 июленә кадәр 2004-2005 елда туган яшүсмерләрне диспансерлаштыру нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсенең үсмерләргә медик-социаль ярдәм бүлегенә һәм Саба һәм Теләче хәрби комиссариатларына мәгълүмат (абсолют саннарда белешмәләр һәм аналитик белешмәлек) бирергә.

3. МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге»нә (Карпова Н.В.) 2004-2005 елда туган яшүсмерләренә «Теләче үзәк

район хастаханәсе» ДАССУ эшләгән график нигезендә, профилактик медицина тикшерүләре уздыруны оештырырга.

4. Районның авыл җирлекләре башлыкларына, «Теләче үзәк район хастаханәсе» ДАССУ эшләгән график нигезендә, 2004-2005 елда туган яшүсмерләрне профилактик медицина тикшерүенә кертүне 100 процент үтәүне тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче Н.Н. Хазипов